**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.11.2018 № ПР-295

**«Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премия турында**

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2015-2018 елларга хокук бозуларны профилактикалау комплексны программасы нигезендә җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

1) 1 нче кушымта нигезендә «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты премиясе турында нигезләмә (алга таба - премия);

2) 2 нче кушымта нигезендә премия бирү комиссиясе составы;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль районы Башкарма
комитеты карары белән расланды
2018 елның «23» ноябреннән № ПР-295
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында нигезләмә

1. «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты премиясе (алга таба - премия) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында бирелә.

2. Премия бирү елга ике тапкыр ярты ел нәтиҗәләре буенча башкарыла.

Һәр ярты еллык өчен өч премия, һәрберсе өчәр мең сум күләмендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм бюджеттан тыш башка чыганаклар хисабына бирелә.

3. Премия бирү өчен кандидатлар булып Татарстан Республикасында хокук саклау юнәлешендәге халык дружиналары һәм иҗтимагый берләшмәләр реестрына кертелгән Актаныш муниципаль районы халык дружиналары әгъзалары тора.

4. Актаныш муниципаль районы халык дружинасы отряды командиры кул куйган премияне бирү өчен кандидатны тәкъдим итү, Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы бүлеге башлыгы тарафыннан килештерелгән комиссиягә җибәрелә, аның составы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана, ярты ел тәмамланганчы 10 көн кала: 20 июньгә кадәр һәм 20 декабрьгә кадәр, әлеге нигезләмәгә кушымта нигезендә, форма буенча ел саен җибәрелә.

5. Премия бирүгә кандидатлар халык дружиналары отрядлары командирларының тәкъдимнәре буенча комиссия утырышында карала.

6. Комиссия үз утырышларына халык дружиналары отрядлары вәкилләрен, дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын, җирле үзидарә органнарын һәм командирларын чакырырга хокуклы.

7. Премияне бирү турындагы карар утырышта катнашучы күпчелек тавыш бирү юлы белән комиссия утырышында кабул ителә.

8. Карар кабул ителгәндә түбәндәге категорияләр исәпкә алына:

1) массакүләм чаралар уздырганда халык дружинасы әгъзасының катнашуы;
2) дежурствога чыгу даимилеге
3) административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау.
4) хокук саклау органнарына җинаятьне ачуда ярдәм күрсәтү.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш узган көннән алып өч көн эчендә тавыш бирүдә катнашкан комиссия рәисе, секретаре һәм барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында нигезләмәгә кушымта

Премияне бирү формасы

Кандидатның Ф.И.А. ____________________________________________

туган елы__________________

Яшәү урыны адресы_____________________________________________
Халык дружинасы отряды исеме һәм эшләү урыны____________________ ___________

Кандидатны Татарстан Республикасында хокук саклау юнәлешендәге халык дружиналары һәм иҗтимагый берләшмәләре реестрына кертү датасы
(көн, ай, ел)______________________________________

Эш урыны, вазифасы______________________________

**Соңгы елда конкрет казанышлар күрсәтелгән характеристика премия бирүгә тәкъдим ителә:**

Халык дружинасы әгъзасының массакүләм чаралар үткәргәндә катнашуы:
________________________________________________________________

Дежурлыкка чыгуның регулярлыгы:_____________________________________

Административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау:
________________________________________________________________
Хокук саклау органнарына җинаятьләрне ачуда ярдәм күрсәтү:
________________________________________________________________

Башка казанышлар:__________________________________________________

Командир
Халык дружинасы отрядлары

___________________ _________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«____»____________20____ел Мөһер урыны

2 нче кушымта
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
расланды
23 ноябрь 2018 ел № ПР-295

Премияләр бирү комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Бариев Илфак Шамил улы | Комиссия рәисе, Башкарма комитет җитәкчесе; |
| 2. | Зиннурова Раилә Рөстәм кызы | Комиссия сәркатибе ; |
| 3. | Латипов Назил Назиф улы | «ФОРПОСТ» МБУ директоры; |
| 4. | Нуриев Фәһим Зәкәри улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 5. | Иманаев Айдар Илфат улы | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |